ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 29.01.2016 г. Казань № 10-5/кс

«Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте өчен эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны исәпләп чыгару буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 27 декабрендәге № 1746-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүче һәм су бүлүне башкаручы «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте өчен, календарь чорларны бүлеп, әлеге карар кушымтасы нигезендә эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифларны билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карарның үз көченә кергән көннән алып 2016 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 29.01.2016 № 10-5/кс
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүчне һәм су бүлүне башкаручы «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте өчен билгеле бер календарь чорларына бүлеп эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы оешма | Эчергә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | Су бүлүгә тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | карарның үз көченә кергән көннән алып | 01.07.2016 алып 31.12.2016кадәр | карарның үз көченә кергән көннән алып | 01.07.2016 алып 31.12.2016кадәр |
| | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге | | | | |
| | «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте | | | | |
| 1 | Берничә технологик яктан бәйләнмәгән үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасы барлыгына нигезләнгән тарифларның дифференциациясе: «Су алу (чистарту корылмалары һәм тышкы коммуникацияләр цехы) кулланучылары өчен – «Салават Купере» торак районы | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 17,69 | 18,08 | | |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | 14,99 | 15,32 | | |
| 2 | Берничә технологик яктан бәйләнмәгән үзәкләштерелгән су бүлү системасы барлыгына нигезләнгән тарифларның дифференциациясе: «Чистарту корылмалары (ташландык суларны нейтральләштерү һәм чистарту цехы) кулланучылары өчен – «Салават Купере» торак районы | | | | |
| 2.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | | | 14,77 | 15,14 |
| 2.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | | | 12,52 | 12,83 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәсе 6 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан чыгып бүлеп бирелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге